# Нәсыйхәт

җомга
30
сентябрь
2011 № 8

**Рәхимле вә Шәфкатьле АЛЛАҺ исеме белән**
**Мамадыш мәдрәсәсенең айлык дини-иҗтимагый газетасы**


# Мәдрәсәдәазан авазы



**23 сентябрьдә Мамадыш мәдрәсәсе базасында шәһәр яшьләре арасында азан әйтү конкурсы үткәрелде.**

Анда 7 яшьтән алып 16 яшькәчә ир-егетләр көч сынашты. Әлеге чараның максаты яшь буында азан әйтүгә мәхәббәт уяту, яшьләрне дөрес итеп, барлык кагыйдәләренә туры китереп азан әйтергә өйрәтү иде. Чараны оештыручылар тагын да олырак максатка ирештеләр: мөселман яшьләрен бергә туплау, аларның арасында бердәмлек булдыру, ислам диненә карата мәхәббәт уяту. Катнашучылар барысы да үзләренең осталыкларын күрсәттеләр, әлегедәй бәйгеләр киләчәктә дә еш үткәрелер диган теләктә калдылар. Чарага катнашучыларның җанатарлары - әниләре, әбиләре һәм дуслары җыелган иде. Алар да үткәрелгән чарадан канәгать калдылар, әлегедәй бәйгеләрнең кирәклеген һәм актуальлеген ассызыкладылар.

Беренче урынны 7 яшьлек Зиятдинов Әдәм яулады. Икенче урынга Минһаҗетдинов Илназ лаек булды. Өченче урынны Юнысов Райнур алды. Хәсәенов Рифат дүртенче булды. Барлык катнашучыларга да истәлекле бүләкләр тапшырылды. Чара азагында чәй эчү дә оештырылды. Берсүзсез азанны мөселманнарның гимны дип әйтсәң ялгыш булмас. Азан әйтүнең савабы һичшиксез күп. "Азан әйтүнең һәм намазда беренче сафтагы савапны әгәр кешеләр белсәләр иде, аны эшләр өчен шобага салырлар иде", "Азан тавышын ишетсә, шайтан 30 чакрым качар",-диган хәдисләр дә бар. Мәдрәсә бәйгедә катнашучыларның барысына да олы рәхмәтен белдерә. Киләсе ярышларда аларның саны тагын да артыр дип өметләнә. Үз нарасыйларына яшьтән Коръән аятьләре, дин гыйлеме өйрәтүче әти-әниләргә, әби-бабайларга Аллаһының рәхмәте булсын диган теләктә кала.

## Яңалыклар

### АЧЫК ИШЕКЛӘР КӨНЕ

8 нче сентябрьдә Мамадыш мәдрәсәсендә ачык ишекләр көне үткәрелде. Бирегә шәһәр һәм авыл мәктәпләре укучылары һәм ата-аналар чакырылган иде. Алар ачык дәреснең шаһите булдылар, вәгазь тыңладылар, викторинада катнаштылар. Килгән кунаклар чарадан канәгать калдылар. Мәдрәсәдә укырга теләк белдерүчеләр дә шактый.

### КАБУЛ ИТҮ КОМИССИЯСЕ ЭШЛИ

Мәдрәсәгә укырга керергә теләүчеләр өчен кабул итү комиссиясе эшли. Биредә уку-укытуга кагылган сорауларга җавап бирәләр, документларны, белешмәләрне кабул итәләр.
Белешмәләр өчен телефон: 3-19-17, 89093148644

### ГОШЕРНЕ–МӘДРӘСӘГӘ

Мәдрәсәдә яңа уку елы дәверенә шәкертләргә җитәрлек ризык туплау, укытучыларга хезмәт хакы түләү өчен финанс булдыру – гаять дәрәҗәдә авыр хезмәт. Шуңа күрә мәдрәсә халыкның ярдәменә мохтаҗ. Хөрмәтле райондашлар! Мәдрәсәбезгә гошер һәм сәдакалар белән ярдәм итик.

### ҖИҺАЗЛАР РЕМОНТЛАНДЫ

Мәдрәсә бинасында косметик ремонт үткәрелде. Уку җиһазлары ремонтланды, буяу һәм чистарту эшләре үткәрелде, уку бүлмәләре төзекләндерелде. Авырлыкларга карамыйча, бу эшләрне мәдрәсә үз көче белән башкарды.

### ЗИРАТТА ӨМӘ

Мамадыш мәдрәсәсе коллективы район хакимияте үткәргән зиратларны җыештыру өмәсендә актив катнашты. Үткәрелгән чара мәдрәсә хезмәткәрләре өчен урынлы булды. Чөнки Ислам кануннарын, тарихны практик рәвештә генә өйрәтү дөрес булмас, мөгаллимнәр үз куллары, эшләре белән моңа якынаерга тиеш.

### ҖЫЕЛЫШ ҮТӘЧӘК

Агымдагы елның 3 нче октябрендә 17.00 сәгатьтә Мамадыш мәдрәсәсендә мәдрәсә каршындагы якшәмбе мәктәпләре һәм кечкә бүлек укучылары һәм укытучылары катнашында җыелыш булачак. Анда укыту барышына кагылышлы мәсьәләләр, дәреслекләр, әдәбият, укыту системасына аерым игътибар биреләчәк, яңа уку елы өчен максатлар куелачак.

### БУШЛАЙ ТҮГӘРӘК

Тиздән Мамадыш мәдрәсәсендә гарәп телен һәм каллиграфиясен өйрәнү буенча түгәрәк башланып китәчәк. Анда гарәп телен, тарихын, шулай ук, Ислам дине нигезләрен тирәнрәк өйрәнергә теләгән һәркем йөри ала. Дәресләр һәр атнаны кечкә якта уздырылачак. Программага җыелышып чәй эчү, төрле фильмнар карау да кертелгән. Курс азагында тыңлаучылар гарәп телендә Коръән укый беләчәкләр, татар халкы тарихы, аның килеп чыгышы турында бик күп мәгълүмат туплаячаклар. Белешмәләр өчен телефон: 3-19-17, 89093148644

# АЕРЫЛЫШУЛАР БИК ЯМАН

**“Дәхи Аллаһның кодрәтенә дәлилләрдәндер сезнең өчен Аллаһның үзегездән хатыннар яратмаклыгы, чөнки һәва Адәмнең кабыргасыннан халык ителде, ул хатыннар белән өлфәтләнеп бергә яшәвегез өчен, дәхи ир белән хатын арасында дуслык һәм мәрхәмәтлек кылды, әлбәттә, Аллаһның бу эшләрендә фикерли белгән кешеләре өчен гыйбрәт бардыр” (Рум, 21).**



Аллаһ ир белән хатынга мәхәббәт һәм мәрхәмәт белән яшәргә кушкан. Дини кануннарга таянып, хөрмәт вә җылы мөнәсәбәтләргә нигезләнгән какшамас гаилә булырга тиеш. Ир белән хатынны ныклы гаилә мөнәсәбәтләре һәм изге балалар тәрбиясе тотып торырга тиеш. Шулай ук, ир белән хатын бер үк нәрсә. Аллаһ болай ди: “Хатыннарыгыз сезгә, сез аларга кием, ягъни хатыннарыгыздан файдаланыгыз да башкаларга күңел төшермәгез” (Бакара, 187). Кием тәнгә сыланып торган шикелле, ир белән хатынның күңелләре дә шулай бер-берсенә якын булырга тиеш. Ләкин һәрбер гаилә дә төрле сынауларга түзә алмый. Шуны да әйтергә кирәк, хәзерге вакытта хәтта мөселман гаиләләрендә дә аерылышу чире бар. Ул һәрбер гаиләгә дә диярлек үтеп керә, бары тик чын иман гына шул чиргә каршы иммунитетны көчәйтә. Шуңа кайбер мөселман кызлары аерылышудан куркып, кияүгә чыкмый торалар. Аерылышу тәртибе исламда күрсәтелгән. Бу мәсьәләгә карата язылган китаплар күп. Аерылышуга караган бүлекләрнең күләме никахлашуга караган бүлекләргә караган ике тапкыр күбрәк. Әлбәттә, бу да кеше тормышында зур урын алып тора. Зәйд ибн Харис Зәйнәп Бинт Җәһимнән аерыла, чөнки кыз бай гаиләдән булгач, Зәйдкә кайчандыр кол булганын гел исенә төшереп тора. Шулай да, Аллаһ аерылышудан ничек булса да котылырга кушты. Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтә: “Рөхсәт ителгән нәрсәләрдән иң начары аерылышу”. Барыбызга да билгеле, Аллаһ кануннары үтәлгән җирләрдә аерылышу азрак. Мәсәлән, сәхабәләр арасында аерылышу бигрәк тә аз була. Безнең бабалар арасында да аерылышу аз булган. Казан, Сембер, Уфа губерналары буенча метрика китапларында аерылышу очраклары бик сирәк күрсәтелгән. Ислам кешеләрне аерылышмаска чакыра. Хатын-кызны ошамаган өчен генә аерып җибәрергә ярамый. Пәйгамбәребез (с.г.в.) болай ди: “Иманлы бәндәләр хатыннарына карата мәрхәмәтсез булмасыннар. Әгәр хатынының бер ягы начар тоелса, яхшы ягы белән канәгать булсын”. “Кемнең күңеле йомшак, шуның иманы яхшырак, ә алар арасында хатыннарына яхшы караганнары хәерлерәк”. Икенче бер риваятьтә әйтелгәнчә, аерылышу сүзеннән Аллаһының тәхете калтырый.

**“Хатыннарыгыз сезгә, сез аларга кием, ягъни хатыннарыгыздан файдаланыгыз да башкаларга күңел төшермәгез” (Бакара, 187).**

Хәләл җефетенең үлеменнән килеп чыккан инфарктлардан икенче урында аерылышканнан соң туган инфарктлар тора. Бер хатын белән генә яшәгәннәрнең гомерләре озынрак була. Аерылышкан ирләрнең психикалары бозыла, хәтта үз-үзен үтерү дәрәҗәсенә кадәр барып җитәләр. Бу фактлар тагын бер кат аерылышуларның кирәкмәгәнлеген күрсәтәләр, чөнки алар начар нәтиҗәләргә китерәләр. Шуңа күрә, аерылышу исламда иң соңгы чара. Зур начарлык эшләмәсәләр, Пәйгамбәребез (с.г.в.) аерылышуны тыйды. Ислам дине гаиләне саклап калыр өчен киңәшләрен бирә. Өйләнешкәннәрнең берсе аерылышырга җыенса, икенчесе аерылмас өчен барысын да эшләргә тиеш. Ләкин ислам дине–практик дин, кайбер очракларда аерылышырга туры килгәнен аңлый. Әлбәттә, килеп туган киеренкелекләр бетерелергә тиешләр. Ләкин барлык мөмкинлекләр дә кулланылса, бүтән өмет калмаса, Коръән кушканча аерылышырга кирәк. Кызганыч ки, хәзерге вакытларда кайбер аерылышуларның бернинди дә нигезләре юк. Аерылышучылар төрле сәбәпләр әйтергә тырышалар, ләкин аларны акларга ярамый. Хакыйкатьтә, мөселман кешесенә аерылышу сүзе дә куркыныч булырга тиеш.

**Ни өчен соң мөселманнар аерылышалар?**

Беренчедән, күбесе никахка дөрес караш белән килми, хәтта аңа әзер дә түгел. Никахның, булачак балалар каршындагы җаваплылыкны аңламау аерылышуга китерә.

Аерылышып, мөселманнар Аллаһ яратмаган гамәл кылалар. Никахка җиңел карап Аллаһының ризалыгына ирешеп була мени? Иманлы кеше моны тирәнтен аңларга тиеш. Аерылырга җыенган кеше булачак балаларының да язмышлары хакында кайгыртамы икән? Алга таба балалары ничек яшәр? Икенчедән, мөселманнар аның нәрсә икәнен аңламыйча башкаралар. Күбесе гаилә турында бик аз гына белә. Өченчедән, гаилә әгъзаларының берсе яки икесе дә эгоист, үз-үзен яратучы булганга, аерылышу килеп чыга. Гаиләнең һәрбер әгъзасы мин-минлектән чыгып эш итә. Дүртенчедән, гыйлемле булсалар да, белемнәрен тормышта куллanмыйлар. Яман гадәтләрдән котылу өчен бер кешенең генә тырышлыгы җитми, ул авыруны терелтер өчен ике нәрсәне күздә тотарга кирәк: берсе – гыйлем, икенчесе – аны куллану. Кызганыч ки, дару ачы булгач, аны кулланырга теләмиләр. Шулай булгач, дәвалану рәхәтен күрмиләр. Бишенчедән, хатыннар ирләренең өстенлеген онытalар. Монда мәхәббәт бетә. Аны ачу алыштыра.

**Бу аерылышу чирләреннән ничек котылырга?**

Беренче чиратта, мөселманнар гаилә кыйммәтләренә кайтырга тиешләр. Ислам буенча гаилә нигезләрен ныгытырга тиешләр. Беркайчан да тормышны үзгәртү соң түгел. Аерылышудан да сакланып калырга була. Һәрбер мөселман да иманын яхшыртырга тиеш. Аларның гаиләсендә килеп туган мәсьәлә аларга ныграк таныш. Замана авыруларыннан сакланыр өчен дә гаилә кыйммәтләрен аңларга тиешләр. Һәрбер атнада да мөселманнар гаиләгә дә игътибар бирергә тиешләр. Ир белән хатын бер-берсе белән күбрәк сөйләшсеннәр. Бер-берсен аңлаганда гына гаилә сакланып кала. Бер-береңне аңламаудан да ызгышлар килеп чыга. Бар гаиләдә дә тормыш чалт аяз була алмый, ләкин мөселманнар сабыр булырга тиешләр. Шул вакытта гына уңышларга ирешеп була. Йорт ашап йоклар өчен генә булырга тиеш түгел. Гаиләдә генә ир белән хатын бергә гыйбадәт кыла. Гел шатлык кына хөкем сөргән гаиләләр юк, ләкин мөмкин кадәр гаиләдә татулыкны һәм бер-береңә ихтирамны арттыру–һәр мөселманның өстендә булган бурычы. Пәйгамбәребез (с.г.в.) сүзләрен искә төшерү урынлы булыр: “Кем хатынына карата иң яхшы мөнәсәбәттә була, шул иң яхшы мөселман була”

**ГАБДРАХМАН ХӘБИБУЛЛИН**

# ИМАНЛЫ БАЛА–НӘСЕЛ КҮРКЕ

**Коръән һәм сөннәткә ышанган мөселман кешесе баланың Аллаһы Тәгаләнең бүләге икәнлеген аңлый. Чөнки тиешле тәрбия алган бала җәмгыятькә файда китерә торган кешегә әверелә, шуның сәбәпле ата-анага Аллаһ тарафыннан зур әҗер ирешә торган була.**



Әмма, иманлы бәндә бала тәрбияләүнең җаваплы эш икәнлеген дә аңлый, чөнки моның өчен ул Кыямәт көнендә соралачагын белә. Аллаһ илчесе (с.г.в.) әйтә: «Сезнең һәрберегез дә көтүче һәм ул үз көтүлеге өчен җавап бирә: ил башлыгы көтүче, ир-ат гаиләсе өчен көтүче, ирнең өен һәм балаларын караган хатын-кыз да көтүче. Димәк, сезнең һәрберегез дә көтүче һәм үз көтүлеге өчен җавап бирә». Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.) балаларга нинди мөнәсәбәттә булырга кирәклеген күрсәтте. Ул алар белән уйнады, кулына алды һәм үбә торган иде. Балаларга карата җылы мөнәсәбәттә булуны ул Аллаһның рәхмәте дип атады. Беркемгә дә сер түгел, балалар сезнең хисләрегезне һәм фикерләрегезне, биргән бәяләрегезне интуицияләре белән кабул итәләр, шуның өчен бала белән мөнәсәбәттә булганда түбәндәге принципларны күздә тоту зарур: баланы хөрмәт итү, шәхесе үсешенә уңай йогынты ясау; аңа кыйммәтен һәм әһәмиятен аңларга ярдәм итү; хаталарын төзәтергә ярдәм итү; үзенә түгел, ә гамәленә бәя бирү; аңа сайлау хокукын бирү; активлыгын, иҗадилыгын үстерү һәм камилләштерү; тиешле карарга килергә рөхсәт итү; таләпләр куйганда әзлеклелеккә өйрәтү; башкаларның да фикерләрен кабул итәргә өйрәтү; балага әчке дөньясын өйрәнергә булышу.

# Сынауны яраткан кешесенә бирә

**Бу дөнья–сынаулар дөньясы. Мин дә бик зур бәлага юлыктым, ярты гәүдәм пеште. Тәнемнең күп урыны өченче дәрәҗәдә пешкән иде. Ул чактагы әрнүләремне үзем генә беләм.**

Район шифаханәсеннән самолет белән Казанга алып киттеләр. Исән калуым икеле иде. Бер ел эчендә сигез тапкыр наркоз кичердем. Билемә кадәр төшеп торган чәчләрем коелып бетте. Аңымны югалтып, берни белми яткан чакларым күп булган. Ирем янымнан бер минутка да китмичә, системаларга хәтле үзе куеп, хәлемнең яхшыга баруына чын күңеленнән сөенеп, күңелемне күтәреп, сабыгырга көч биреп торды. Хәлләрем бик-бик авыр иде. Мин һәрвакыт Аллаһның барлыгына, берлегенә ышанып, теләкләр теләдем. “Исән-сау терелеп, аякларыма басып, балаларым янына кайта алсам, иң беренче газиз әнкәйләремнең икесенә дә, башларына ак яулык алып кайтып бәйләр һәм кул-аякларым төзәлгәч, ятим балалар йортында тәрбияләнүче балаларга бәлеш пешереп алып барыр идем,”–дидем. Әлхәмдүлилләһ, әйткән нәзерләремне бераз аякка басу белән үтәдем. Минем бит әле ике ай элек бердәнбер туганым, апам гүр иясе булган иде. Аның иң кечкенә балаларын, үзебезнең өч балабыз янына тәрбиягә алган идек. Аллаһы Тәгалә ярдәменнән ташламый, бәлки шул балалар хакына, миңа гомер биргәндер. Әйтәләр бит Раббыбыз чирне дә, кайгыны да яраткан кешесенә бирә дип. Шул сынауларга сабыр итсәң, алдагы көннәреңдә рәхәттә яшәтә ди. Бик тә дөрес бу сүзләр.

Ул миңа алга таба да яңадан-яңа авыруларны биреп торды һәм сихәтен дә бирде. Язып бетерә торган түгел ул чакта шифаханә юлларын таптауны. Табиблар да минем терелүемә ышанмадылар. Беркайчан да нигә генә бирә бу чирләрне Аллаһы Тәгалә дип әйтмәдем. Терелүемә өметләндем. Гел Аллаһка ялвардым. Авырулар артта калып, бик тә рәхәттә яши башлагач, бәхетебезгә әллә нинди күзләр тиде, тагын бер сынау килде: ирем үз теләге белән ахирәткә китеп барды. Ни өчен, ни булганын белмәдек тә. Бу кайгыны мин бик авыр кичердем. Күгемне кара болытлар каплагандай куркыныч булды. “Ничекләр яшәрмен аннан башка?!”–дип, югалып калдым. Ирем үлеп ике ел узгач, ике әнием, бер атна эчендә гүр ияләре булдылар. Шушы кайгылардан сабыр итәргә миңа догалар булышты Аллаһы Тәгаләдән сабырлыклар сорадым. Алар рухына догалар кылып, үз-үземне юаттым. Бүгенге көндә бар да яхшы: балаларым барысы да гаиләле, биш оныгым үсеп килә. Үзем йөгерә-йөгерә эшләп йөрим, барысына да шөкер итеп яшим. Намазлар укыган саен, Аллаһы Тәгаләдән сәламәтлек, һәм дә бала хәсрәтләре бирмәвен сорыйм.

**МӨНИРӘ НӘБИУЛЛИНА.**

**2 курс шәкерте.**

## Сорау илә җавап

**КАБЕР ЯНЫНДА КОРЪӘН УКЫРГА БУЛАМЫ?**

**Каберләр янында, зиратларда мәрхүмнәр рухына багышлап, һәрчак Коръән укыганнар. Тик соңгы вакытларда моның исламда катгый рәвештә тыелган булуы турында сүзләр йөри. Нишләргә? Изге китаптан чыгып караганда, кайсы тәҗрибә дөресләккә күбрәк туры килә?**

Мәрхүмнең рухына багышлап укылган Коръәннең файдасы турында мондый бер хәдистә әйтелә: «Бервакыт Мөхәммәд Пәйгамбәр Мәдинәдәге зират яныннан узып барганда үз каберләрендә каты газап кичергән кешеләрнең тавышларын ишетә. Аллаһның илчесе шулчагында: «Алар кече гөнаһлары өчен шулай газап кичерә»,-дип әйтеп куя. Аннары шунда ук үзен төзәтеп: «Юк, зур гөнаһлар өчен газап кичерәләр. Берсе кече йомышны үтәгәндә тәртипсез булды, икенчесе башкаларга яла якты һәм гайбәт сөйләде»,-диде. Бу сүзләрдән соң Пәйгамбәр үзенә пальма ботагын китереп бирүләрен сорады. Аңа аны китереп биргәч, ул әлеге ботакны икегә сындырды да, һәр кабергә шуның яртысын кадады. Сәхабәләр аннан ни өчен шулай эшләвенең сәбәбен сорадылар. Ул: «Бу таяклар аларның хәлен җиңеләйтүе ихтимал һәм әлеге фараз кылынган җиңеллек таяклар кибеп беткәнчегә кадәр дәвам итәчәк»,-дип җавап бирде.

Танылган ислам галиме, имам әл-Хаттаби бу хәдискә таянып: «Әлеге хәдис каберләрдә Коръән укуның мөстәхәб (уңай хәл) булуы хакында сөйли. Агачның тәсбихыннан мәрхүмгә җиңеллек килгәч, кабер янында укылган Коръәннән бәрәкәт күбрәк була һәм мәрхүмгә барып җитәргә мөмкин»,–ди.

Гомәр ибн әл-Хаттабның улы Габдулла ибн Гомәр үзенең каберендә изге китаптагы икенче сүрә, ягъни әл-Бакара укылсын дип васыять әйтеп калдырган.

**Сорауларга җаваплар umma.ru сайтыннан алып тәрҗемә ителде.**

# Хаҗ–фарыз гамәл

Күңелебез тулды шатлык белән,
Чыктык бергә бу олы юлга,
Раббым насыйп итсен хаҗыбызның
Барча гамәлен үтәп кайтырга.
Жыелдык без күп урыннан:
Бистән, Мәскәү, Әләзән, Черкли авылыннан,
Индеркадан, Дәхтәрнидән, Кузнәйдән.
Киткән көнне авыл шау-гөр килә,
Жыелганнар яшьләр һәм картлар.
Авылдашларыбыз сәдакалар биреп,
Дога кылып озатып калдылар.
Бик зур бурыч алдык үзебезгә
Авылдашларыбыз каршында.
Бөтен картлар, яшьләр арасында
Үрнәк булып кирәк яшәргә.
Зур самолет Самарадан алып
Китте безне ерак җирләргә.
Менә Кара диңгез һавасыннан очып,
Юнәләбез гарәп җиренә.
Йөрәкләр калтырап тора: көчебез җитәрме
Раббым кушканнарны үтәргә?!
Без Синең каршыңа барабыз бит,
Чын күңелдән гафу сорарга.
Кара диңгезне үттек, хәзер инде
Биек таулар, кырлар кичәбез.
Алар артта кала, без күрмибез аны,
9000 метр өстә очабыз.
Жидда шәһәренә килеп җиттек,
Тиздән Мәдинәгә барырга.
Рәсүлебезнең (с.г.с.) торган, үлгән җирен
Үз күзебез белән күрергә.
Менә Мәдинә шәһәре, һәр көн җыелып,
Пәйгамбәребезнең (с.г.с) каберен күрәбез.
Гөнаһларыбыздан тәүбә кылып,
Намаз укып, дога кылабыз.
Жәннәт бакчасына кердек шундый матур,
Йөрәкләребез әллә нишләнә.
Раббым, насыйп булсын изгеләр сафында
Жәннәтләрдә бергә булырга.
Мәдинәнең фазыйләтле урыннары–Ухуд,
Каты сугыш булган ул тау янында.
Хәмзә (р.а) белән шунда күп сәхабә
Шаһит булган ислам юлында.
Жиде мәчет урынында булдык,
Сәхабәләр аны салдырган.
Ике кыйбла мәчетен дә күрдек,
Куба мәчетендә намаз укыдык.
Авыр тавы бик күп серләр саклый,
Анда тау куышы сакланган.
Шунда Рәсүл якын дусты белән
Дошманнан качып котылган.
Мәдинә ул изге шәһәр, күңелләрдә
Онытылмаслык тәэсир калдыра.
Бәлки кайсыбызга шул җирләргә
Насыйп булыр тагын килергә.
Мәдинәдән чыгып Микать дигән җирдә
Ихрам киеп киттек Мәккәгә.
Кече хаҗны–гомрә гамәлләрен
Үтәр өчен бардык мәчет Хәрамгә.
Күз яуларын алырлык бу мәчет
Килеп басты безнең каршыга.
Кем уйлаган гади татар хатыны
Басар шунда Раббым каршына.
Ләббәйкә, Аллаһумә, Ләббәйкә,–дип
Килдек Кәгъбәтулла янына.
Раббым йортын бергә тәваф кылдык,
Гөнаһлардан гафу сорадык.
Сафа-Марва таулары арасында
Бик күп зикер әйттек Аллаһка.
Дөнья–ахирәт хәзинәсен бир, дип,
Бөтен мөэмин бәндәләреңә.
Үзебезгә, балаларыбызга,
Оныкларга, кияү-киленгә,
Тирә-күршеләргә, дус-ишләргә,
Кардәшләргә, авыл халкына.
Гарәфәт тавы–изге тау,
Анда булу–ул изге гамәл,
Андагы Рәхмәт тавына менеп,
Раббымның рәхмәтен теләдең.
Аның янындагы Хира тавы–
Изге урын, аның өстендә
Пәйгамбәргә (с.г.с.) Коръән, аять-аять
Иңә башлаган дөнья йөзенә.
Гарәфәт көн... Көне буе Гарәфәт тавында
Зикер кылдык, Раббым, үзеңә,
Намаз укып, хаҗәтләрне сорап,
Ахшамгача кирәк торырга.
Миңа дигән җирдә палаткада
Туры килде өч көн яшәргә.
Аннан бергә-бергә таш бәрергә
Жәяү йөрдек ничә мәртәбә.
Таш бәрүнең фазыйләте:
Син үзеңне пакьлыйсың,
Эчеңдәге бөтен начарлыкны
Чын күңелдән алып ташлыйсың.
Бәйрәм көнне иртәнге намазны
Мөздәлифәгә юнәлдек укырга.
Гарәфәт тавыннан Мәккәгәчә
Халык төркеме туктаусыз ага.
Аннан өебезгә җәяү кайттык,
Тагын Хәрам мәчетенә юнәлдек.
Кәгъбәтулланы тагын тәваф кылып
Олы хаҗның фарызын үтәдек.
Бик дус тордык, бүлмәләрдә
4-6 шар кеше яшәдек.
Изге җир күңелләрне йомшарта,
Кешеләрдә шәфкать арттыра.
Табибларыбыз бөтен хаҗиларга
Көчен кызганмыйча булыша.
Яшьләребез олы кешеләргә
Ярдәм итәр өчен ашыга.
Бәхетлеләр Хәрам мәчетенә барып,
Бик күп намаз укып йөрделәр,
Чөнки ул намазның савaплары
100 мең мәртәбә артык,–диделәр.
Күп мәртәбә Гайшә мәчетендә ихрам баглап,
Кайттык һаман мәчет Хәрамгә.
Вафат булган кардәшләребез өчен
Кече хаҗ–гомрә кылырга.
Кәгъбәтулла шундый мәхәббәтле, анда
Коръән аятьләре язылган.
Алтын хәрефләре күзне чагылдыра
Насыйп булды шуны күрергә.
Тәртип яхшы, безнең хәзрәт
Күңелләребезне йомшартты.
Рәхмәт аңа һәм ярдәмчеләргә,
Бик күп нәрсә безгә аңлатты.
Онытылмаслык алган дәресләрне,
Тормышта да юмарт булыйк.
Пәйгамбәребез (с.г.с.) сызган юлдан барып
Чын кешеләр булып яшик.
Хәлдән килгән гамәлләрне кылып,
Хаҗи абыйлар һәм апалар.
Айдан артык изге җирдә торып,
Бүген өйләренә китәләр.
Раббым, Үз каршыңа килдек
Шундый олы бурыч үтәргә.
Кабул кыл Син бөтен гамәлләрне,
Гөнаһларыбыз гафу ит.
Син иң Олы, Көчле, Син белүче,
Бөтенебез Синең каршыңда
Авыр көндә Син ярдәм бирүче
Юктан бар кылган колларыңа.

**ФАТЫЙМА САЛИХОВА.**

## Белдерүләр

*Мәдрәсә базасында атнаның һәр ялында балалар өчен әхлак дәресләре алып барыла. Укуларга рәхим итегез.

*Мәдрәсә бинасында ислам атрибутикасы кибете эшли. (Коръән китаплары, шамаилләр, тмин майлары, дисбеләр, дини китаплар, түбәтәйләр һ.б.)

*Мәдрәсә базасында таныштыру бүлеге эшли.

Тел. 89625504168, 89372991485

*Балага исем кушу, никах уку һәм башка дини мөрәсимләрне үткәрү. Мамадыш мәдрәсәсе, М. Жәлил урамы, 8/28)

*Намаз, Коръән укырга, дин гыйлемен өйрәнергә теләгән һәр кешене мәдрәсәдә оештырылган кичке уку курсларына чакырабыз.

*Мамадыш мәдрәсәсе фәкыйрь –мескеннәргә, ятим балаларга тарату өчен кулланылган киемнәр кабул итә.

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең Бөек исемнәре булганга күрә, аны саклап тотуыгыз сорала**

**Баш мөхәррир: Хәбибуллин А.М. Мөхәррир урынбасары: Хәбибуллина Э.Р.**
**Дизайн һәм верстка: Мингалиева Ф.Н. Жаваплы сәркатип: Спиридонова А.С.**
**Безнең адрес: Мамадыш шәһәре, Муса Жәлил урамы,8/28. mamadysh-medrese@mail.ru. Газета “Татмедиа” ААЖнең Мамадыш муниципаль районы”Нократ” мәгълүмат-матбугат филиалында басылды. Тираж татар телендә 100 данә.**